КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 5 март г.Казань № 123

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Наркотиклар кулланудан туктаган затларның хезмәт социализациясе проектларын тормышка ашыручы иҗтимагый оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау» 2014 ел, 7 июль, 455 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Наркотиклар кулланудан туктаган затларның хезмәт социализациясе проектларын тормышка ашыручы иҗтимагый оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау» 2014 ел, 7 июль, 455 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 21 июнь, 418 нче; 2017 ел, 19 октябрь, 796 нчы; 2020 ел, 26 июнь, 534 нче; 2021 ел, 31 май, 420 нче; 2022 ел, 19 февраль, 139 нчы; 2022 ел, 7 июль, 650 нче; 2022 ел, 29 ноябрь, 1267 нче; 2023 ел, 11 март, 236 нчы; 2023 ел, 26 май, 642 нче; 2023 ел, 3 июль, 782 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 16 октябрь, 764 нче карары белән расланган «Җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

әлеге карар белән расланган Наркотиклар кулланудан туктаган затларның хезмәт социализациясе проектларын тормышка ашыручы иҗтимагый оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

1.1 пунктта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 16 октябрь, 764 нче карары белән расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» дәүләт программасы» сүзләрен «Җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 16 октябрь, 764 нче карары белән расланган «Җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» дәүләт программасы» сүзләренә алмаштырырга;

2.2 пунктның унбишенче абзацына «(булганда)» сүзләрен өстәргә.

2. Бу карар (бу карарның 2024 елның 1 июненнән үз көченә керә торган 1 пунктындагы алтынчы абзацыннан тыш) рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин